ЧӘРШӘМБЕ
13
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 10 (6732)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

УКУ ЕЛЫ ДӘВАМ ИТӘ

Кышкы каникуллардан соң, совет балалары яңа көч, яңа дәрт белән укуны яңадан дәвам иттерә башладылар. Уку елының икенче яртысы башланды. Безнең мәктәп балалары өчен, совет укытучылары өчен бу, әлбәттә, күңелле хәл. Явыз дошманга каршы бөек Ватан сугышының авыр шартларында уку - укыту эшләренең нормаль рәвештә дәвам итүе,—ул бик күп нәрсәләр турында сөйли. Барыннан да әлек, ул Совет хөкүмәтенең һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның мәктәпләр турында, совет балаларына коммунистик тәрбия бирү турында кайгыртучанлык күрсәтүләрен тагын һәм тагын бер тапкыр ачык раслаучы факт булып тора.

Киләчәк буынга—совет балаларына белем бирү, аларны югары дәрәҗәдәге культуралы кешеләр итеп, чын совет патриотлары итеп тәрбияләү турында мондый кайгыртучанлык күрсәтүгә уку-укыту эшләре сыйфатының иң югары дәрәҗәгә күтәрелүе белән җавап бирергә кирәк. Совет педагогларының, профсоюз һәм комсомол оешмаларының бурычы исә нәкъ шул сыйфат өчен көрәшне берничә тапкыр көчәйтүдән, балаларга коммунистик тәрбия бирү өчен көрәштә укытучылар коллективлары һәм укучы балалар арасында социалистик ярышны киң оештырудан гыйбарәт. Мәктәпләрдә аңлы дисциплина булдыру,—ул, уку-укыту эшендә югары уңышка ирешүдә төп шартларның берсе.

Уку елының беренче яртысына карата кайбер йомгаклар республикабызда уку-укыту эшләренең нәтиҗәсе начар түгел икәнлекне күрсәтә. Күп кенә мәктәпләрдә укытучылар яхшы күрсәткечләргә ирештеләр. Бу яктан Әгерҗе районындагы кайбер мәктәпләрне аеруча күрсәтеп үтәргә мөмкин. Ижбайки, Мордва, Тоба мәктәпләрендә һәм кайбер башкаларында йөреш 100 процент тәшкил итә. Иске Аккужа—башлангыч мәктәп укытучысы Фәйзуллина, Тәбәрле мәктәбе укытучысы Якупова, Тирсә мәктәбендә укытучы Хәбирова, Нәбиуллина һәм башка иптәшләр уртача 95—100 процент өлгереш бирәләр. Бу, намуслы хезмәт нәтиҗәсе; бу, үз-үзеңне аямыйча эшләүнең, иҗат итүнең һәм тырышлыкның гүзәл нәтиҗәсе.

Уку елының беренче яртысы йомгаклары, алар нинди генә булмасын, башны әйләндермәскә тиешләр. Бүген яхшы эшләргә, ә иртәгә аннан да яхшырак эшләргә! Әнә шундый бурыч куелырга тиеш. Ә моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Бары тик инициатива, тапкырлык кирәк. Үзеңә тапшырылган эшне намус белән башкару өчен җаваплылык сизү кирәк. Билгеле, сугыш вакыты кыенлыклары юк түгел. Ләкин алар безнең уку-укыту эшләребезне йомшартуга һич тә тәэсир итмәскә тиешләр. Кыенлыкларга каршы барырга һәм аларны җиңәргә! Лозунг әнә шундый. Алдынгы мәктәпләрнең, алдынгы коллективларның эш тәҗрибәсе бу лозунгның уңышлы үтәлүен ачык күрсәтә.

Үткән елны республикабызда ун меңнәрчә мәктәп балалары һәм пионерлар авыл хуҗалыгы эшләрендә актив катнаштылар һәм матур күрсәткечләр бирделәр. Моңа безнең мәктәпләребездә уку-укыту эшләренең практикага бәйләп алып барылуы нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Ватан сугышы чорында исә моның әһәмияте аеруча үсте. Шунлыктан, балаларны практик эшкә өйрәтү тәрбия эшләрендә төп урыннарның берсен алырга тиеш. Укучы балаларга хәрби белем бирү дә шулай ук иң мөһим бурычларның берсе. Бу өлкәдә әле күп эшләргә кирәк һәм уку елының ахырынача, әлбәттә, яхшы нәтиҗәләргә ирешелергә тиеш.

Алда зур һәм мактаулы бурычлар тора. Алар турында инде укытучыларның январь конференцияләрендә атап әйтелде. Хәзер җиң сызганып, ныклы эшкә, укытучы иптәшләр!

ВКП(б) Үзәк Комитеты, иптәш СТАЛИНГА

Кадерле иптәш Сталин!

Безнең барлык фикерләребез һәм хисләребез—Кызыл Армия белән, Сезнең даһи җитәкчелегегездәге бу армия немец - фашист басып алучыларга удар артыннан удар ясый. «Правда» редакциясенең һәм издательствосының, Сталин исемендәге «Правда» газетасы типографиясенең работниклары; дошманны тар-мар итү буенча бөтен халык эшенә үзләренең акчаларын кертергә теләп, танклар төзүгә 430 мең сум җыйдылар. Средство җыю дәвам итә. Төзелгән сугыш машиналарына «Правда» исемен бирүне Сездән үтенәбез.

Сезгә, туганыбыз Иосиф Виссарионович, чын йөрәктән озын һәм озын гомер, хезмәт иляре бәхете өчен яхшы сәламәтлек телибез.

«Правда» редакторы **П. ПОСПЕЛОВ.**
Редакциянең партбюро секретаре **М. ДОМРАЧЕВ.**
Издательство һәм типография директоры **А. РЕВИН.**
Издательство һәм типография партбюросы секретаре **А. АРОНОВА.**

„Правда“ газетасы редакторы иптәш П. ПОСПЕЛОВКА, Редакциянең партбюро секретаре иптәш М. ДОМРАЧЕВКА, Издательство һәм типография директоры иптәш А. РЕВИНГА, Издательство һәм типография партбюросы секретаре иптәш А. АРОНОВАГА

«Правда» исемендә танклар колоннасы төзүгә 430.000 сум җыйган «Правда» редакциясе һәм издательствосы; «Правда» газетасы типографиясе работникларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль, Оборона Халык Комиссары И. В. СТАЛИНГА

Сезнең турыдан-туры җитәкчелегегездә Ватан сугышы фронтларында фашистик армияләрне тар-мар итүче Кызыл Армиянең сугышчан уңышлары округ частьларының личный составын, аларның семьяларын һәм фронтовик командирларның семьяларын рухландыра. Безнең бөек Ватаныбызның колхозчыларыннан һәм барлык патриотларыннан үрнәк алып, фронтовиклар хатыннары берничә көн эчендә «Боевая подруга» исемле самолетлар эскадрильясенә 790.000 сум акча җыйдылар һәм Дәүләт банкысына керттеләр, шуның өстенә СИБВО ның кызылармеецлары, курсантлары, командирлары соңгы көннәрдә Кызыл Армия өчен кораллар алуга 7.446.000 сум җыйдылар. Ленин—Сталин партиясенә, үзенең социалистик ватанына бирелгәнлекнең, Кызыл Армиягә. Сезгә, иптәш Сталин, аның сөекле юлбашчысына, остазыбызга һәм даһи полководецка чиксез мәхәббәтнең көчле демонстрациясе сыйфатында средстволар җыю уңышлы рәвештә дәвам итә.

СИБВО гаскәрләре командующие генерал-лейтенант **МЕДВЕДЕВ**
СИБВО хәрби советы члены генерал-майор **КОЛОБЯКОВ.**
СИБВО политуправлениесе начальнигы полковник **ЗАХАРЫЧЕВ.**

Москва, ВКП(б) Үзәк Комитеты иптәш СТАЛИНГА

Анабыз Ватанга һәм Сезгә, иптәш Сталин, мәхәббәт белән рухланып, 1962 нче номерлы частьның сугышчылары һәм командирлары, бөек совет халкының ихтыярын үтәргә—кабахәт дошманны тар-мар итәргә хәзер торган хәлдә, «Гвардеец» исемле танклар колоннасы төзүгә 4.552.342 сум керттеләр. Средство керү дәвам итә. Сезнең җитәкчелегегездә совет халыкларының изге җире фашистик шакшыдан чистартылачак, дошман тар-мар ителәчәк. Без моңа тирәнтен ышанабыз.

Немец оккупантларына үлем!

ХАЛЮЗИН, ИСТОМИН.

Москва, Кремль, иптәш СТАЛИНГА

Беренче һава десанты гвардия дивизиясе сугышчылары, командирлары һәм политработниклары «Сталинский десантник»исемле эскадрильяләр төзүгә үзләренең саклык акчаларыннан 1.324.500 сум керттеләр. Средство җыю дәвам итә.

Кадерле Иосиф Виссарионович, без беләбез, халкыбызның саклык акчаларына төзелгән самолетлар безнең җиңүебезне һәм фашистик гаскәрләрнең тар-мар ителүен тизләтәчәк. Без, гвардеец-десантниклар, Сезнең һәрбер приказыгызны намус белән үтәргә ант итәбез.

Немец оккупантларына үлем!

Беренче һава десанты гвардия дивизиясе командиры гвардия генерал-майоры **КАЗАНКИН.**

Москва, Кремль, иптәш СТАЛИНГА

Кызыл Армиянең уңышлы һөҗүме белән рухланып, безнең колхозның колхозчылары үзләренең саклык акчаларыннан «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 38 мең сум акча җыйдылар, үзләренең запасларыннан Кызыл Армия фондына 300 пот ашлык бирделәр. Безнең колхоз 40 хуҗалыктан тора һәм безнең заманның бөек очучысы Валерий Павлович Чкалов исемен йөртә. Сезгә, иптәш Сталин, сүз бирәбез, безнең колхоз барлык төр тапшырулар буенча үзенең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен вакытыннан элек үтәде һәм үзенә бирелгән бөек исемне киләчәктә дә аклар.

Колхоз председателе **САДЫЙКОВ.**
Татарстан АССР ның Чаллы районы.

НОРЛАТ, ТАТАРСТАН АССР

ВКП(б) ның Октябрь райкомы секретаре иптәш ЯМКОВКА

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 2.538.000 сум акча җыйган, Кызыл Армия фондына 12.566 пот һәм промышленность эшчеләре өчен 4.000 пот ашлык тапшырган Октябрь районы колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль, иптәш СТАЛИНГА

Безнең туганыбыз героик Кызыл Армиягә ярдәм итүгә гаять зур теләкләрен белдереп, совет элемтәчеләре; «Совет элемтәчесе» исемле танклар колоннасы төзүгә акча җыя башладылар. 1.565.300 сум җыелды һәм Дәүләт банкысына тапшырылды инде.

Профсоюзларның барлык членнарын профсоюзлар исемендәге танк колонналары һәм самолетлары эскадрильяләре төзүгә средстволар җыя башларга чакырабыз.

Үзәктәге элемтә работниклары профсоюзы Үзәк Комитеты Председателе **Н. БАХГОРСКИЙ.**

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

ЯЗУЧЫ АЛЕКСЕЙ НИКОЛАЕВИЧ ТОЛСТОЙНЫ ХЕЗМӘТ КЫЗЫЛ БАЙРАГЫ ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

Әдәбият өлкәсендә күренекле хезмәтләре өчен, туууына 60 ел тулу көне уңае белән Сталин премиясе лауреаты, академик язучы Алексей Николаевич Толостойны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе **М. КАЛИНИН.**
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре **А. ГОРКИН.**

Моска, Кремль. 10 январь, 1943 ел.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

12 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

12 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның түбәнге агымы районында, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

Безнең очучылар дошманның портларыннан берсенә һөҗүм вакытында немецларның 5.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең частьлар штурм группалары булып дошманның терәк пунктларын юк иттеләр. Участокларның берсендә командиры иптәш Осечкин булган подразделениенең сугышчылары гитлерчыларның позицияләренә үтеп керделәр һәм 6 орудие, 3 миномет, берничә дистә винтовка һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең артиллерия уты белән дошманның бик күп ДЗОТ лары һәм блиндажлары юк ителде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман, совет частьларының алга баруын тоткарларга маташа һәм сугышка пехота һәм танкларның зур көчләрен кертә. Участокларның берсендә гитлерчылар 100 гә якын танк тупладылар һәм бик каты контратакалар ясадылар. Безнең частьлар дошманның барлык контратакаларын кире кайтардылар, немецларның 17 танкысын сафтан чыгардылар һәм 300 дән артык солдат һәм офицерларын кырып ташладылар. Икенче бер участокта Н-че часть гвардеецлары ике көн эчендә немецларның 6 танкысын, 19 кыр һәм 2 автомат пушкасын, 34 пулеметын, 19 автомашинасын, бер сугыш припаслары складын һәм бер азык складын кулга төшерделәр.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Великие Лукидан көньяк-көнбатыштагы районда, немецлар командованиесе гаять күп кешеләрен һәм техникасын югалтуга да карамастан, контратакага яңадан пехота һәм танкларның зур көчләрен җибәрә. Гитлерчыларның контратакаларын кире кайтарып, безнең частьлар дошманны авыр югалтуларга дучар итәләр. Тик бер участокта гына да немецлар, үтерелгән хәлдә генә дә, 500 гә якын солдат һәм офицерларын югалттылар, 75 немец плен алынды. Икенче бер участокта безнең сугышчылар немецларның 11 танкысын юк иттеләр. Шуның өстенә совет подразделениеләре бер рота дошман автоматчикларын чолгап алдылар һәм бөтенләй кырып ташладылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә һөҗүмне дәвам иттерделәр. Безнең моторлаштырылган һәм танк подразделениеләребез Минеральные Воды шәһәренә һөҗүм итеп кергән вакытта, тимер юл станциясендә немецларның гаскәрләр һәм сугыш милекләре төялгән 2 эшелоны җибәрергә әзерләнеп куелган булган. Совет сугышчылары вагонларда булган дошман солдатларын юк иттеләр һәм эшелоннарны кулга төшерделәр. Икенче бер участокта Н-че кавалерия часте дошманның оборонасын җимереп, сугыша-сугыша 20 километрга алга китте. Тулы булмаган мәгълүматларга караганда, 400 гә якын гитлерчы юк ителгән. 9 орудие, 26 автомашина, 15 миномет, 19 пулемет, танкка каршы ата торган 34 мылтык, 300 винтовка һәм автоматлар кулга төшерелде. Бу участокта 200 дән артык гитлерчы плен алынды.

* * *

Төньяк-көнбатыш фронтта истребитель очучылардан Смирнов, Углянский, Родин һәм Грачев иптәшләр немецларның 8 «Мессершмитт» лары белән сугышка керештеләр. Совет очучылары дошманның 4 самолетын атып төшерделәр һәм үзләренең аэродромнарына исән-сау кайттылар.

* * *

Сумы өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннар отрядының бер группасын венгерларның бер ротасы чолгап алган. Совет патриотлары төрле яктан оборона оештырганнар, дошманны якын арага җибәргәннәр һәм аңа ут ачканнар. Сугыш нәтиҗәсендә венгерлар, 44 кешеләрен югалтып, кире чигенгәннәр, Украина партизаннарының «За родину» дигән отряды сугыш хәрәкәтләренең 7 көне эчендә немецларның 177 солдатын һәм офицерын, бер бронемашинасын, берничә автомашинасын һәм азык саклана торган 2 складын юк иткән.

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсенең Большинский авыл советына караган «Свободный труд» колхозында немец-фашист кабахәтләр эшләгән талаулар турында акт игълан ителә: «Немец басып алучылар колхозда 166 дуңгызны, 95 баш мөгезле эре һәм вак терлекне, 897 баш йорт кошларын, 452 центнер көнбагышны, 200 центнер солыны, 30 центнер бодай һәм арпаны тартып алганнар. Гитлерчы бандитлар бу колхозга 151.910 сум зарар китергәннәр. Шуның өстенә немецлар колхозчыларны талаганнар, аларның аяк киемнәрен, өс киемнәрен һәм башка кыйммәтле әйберләрен талаганнар». Актка кул куйдылар: колхоз председателе Недайводин һәм бухгалтер Хрусталев».

* * *

Югославия партизаннары Теслич шәһәре өчен булган сугышларда дошманның 2.000 гә якын кешедән торган гарнизонын тар-мар иткәннәр. Партизаннар күп санда пленныйлар, шул исәптән немецларның бер полковнигын һәм дошманның башка офицерларын плен алганнар. Партизаннар кулына бик күп трофейлар төшкән. Алар бик күп орудие, ә шул исәптән 4 гаубица, танкка каршы ата торган 3 пушка, 2.000 винтовка, 8 паровоз, 30 вагон, күп кенә снарядлар һәм башка хәрби милекләр кулга төшергәннәр.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: Сталинград районында безнең гаскәрләр тарафыннан кулга төшерелгән трофейлар.

ТАСС фотохроникасы.

ТАНК КОЛОННАЛАРЫ һӘМ САМОЛЕТ ЭСКАДРИЛЬЯЛӘРЕ ТӨЗҮГӘ!

Татарстанның барлык пионерларына һәм мәктәп балаларына

АЗНАКАЙ ПИОНЕРЛАРЫНЫҢ МӨРӘҖӘГАТЕ

Үткән елда Татарстан пионерлары тарафыннан тупланган средствога төзелгән самолетның героик көрәше турында газеталарда укыгач, без, Азнакай районының Сәпәй тулы булмаган урта мәктәбенең укучылары, пионерлары һәм комсомолецлары «Татарстан пионеры» исемле яңа самолет төзү өчен акча тупларга уйладык. Без кыска вакыт эчендә 5.000 сум акча җыйдык. Акча туплауны тагын да дәвам иттерәбез.

Без Татарстанның барлык пионерларына һәм укучыларына мөрәҗәгать итеп әйтәбез: безнең бәхетебезне саклау өчен көрәшүче Кызыл Армиябез дошманны тизрәк тар-мар итсен өчен без, балалар да, кулыбыздан килгән бөтен ярдәмне күрсәтергә тиешбез. «Татарстан пионеры» исемле самолет төзүгә республикабызның барлык пионерлары һәм укучылары зур активлык белән катнашырлар дип көтәбез.

Кеше ашаучы гитлерчылар өеренә үлем!

350 укучы һәм пионерларның тапшырулары буенча мөрәҗәгатькә кул куйдылар:

Өлкән пионер вожатые ӘХМЕТШИНА, учком председателе МИРГАСЫЙМОВА, укучылардан: ӘХМӘДИЕВА һәм МАНСУРОВА.

Самолетлар эскадрильясе төзүгә

БАЛТАЧ, 12 январь. **(Телефон буенча).** Самолетлар эскадрильясе төзүгә акча җыюны беренче булып Янгул авыл советына караган «Яңа тормыш» һәм Тимошенко исемендәге колхоз члennары башлап җибәрделәр. «Яңа тормыш» колхозы члены, фронтовик хатыны иптәш Нургалиева 5.000 сум акча һәм Кызыл Армиянең 25 еллык бәйрәме уңае белән фронтовикларга бер пар киез итеклек йон бүләк итте. Колхоз тегермәне мөдире иптәш Сәйфиева самолетлар төзү фондына 2.000 сум, тегермәндә эшләүче Әгъзам Зарипов һәм Әхмәтҗан Маннапов иптәшләр 4.000 әр сум бирделәр. Тимошенко исемендәге колхоз члены Сабир иптәш Әхмәтҗанов та 4.000 сум, «Большевик» колхозында эшләүче тракторчы иптәш Ромазанов 10.000 сум бирделәр. Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән «Яңа тормыш» колхозы члennары Шакиров, Гыйльмуллин, Хәбибуллин һәм Әхметшин иптәшләр фронтовикларга җибәрү өчен берәр сарык бүләк иттеләр.

* * *

ЧҮПРӘЛЕ, 12 январь. **(Телефон буенча).** «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы фондына һәм самолетлар эскадрильясе төзүгә средство туплауны колхозчылар зур оешканлык белән дәвам иттерәләр. Район буенча барлыгы 3.805.000 сум акча җыелды. Шуннан 1.252.000 сумы самолетлар эскадрильясе төзү өчен тапшырылды.

Колхозчылар Кызыл Армия фондына продуктлар тапшыруны дәвам иттерәләр. Район буенча Кызыл Армия фондына 80 сарык, 99 каз, 160 тавык, 1 центнер бал, 70 килограмм май, 112 тире һәм 50 килограмм йон җыелды.

ЭШЛЕКЛЕ ҖАВАП

ЧИСТАЙ, 12 январь. **(Телефон буенча).** Тат. Талкыш авыл советына караган колхозларның члennары «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү фондына акча туплауга актив катнашалар. Алар 200.000 сумнан артык акча җыйдылар. Колхозчылар иптәш Сталинның телеграммасына җавап итеп, самолетлар эскадрильясе төзүгә яңадан 100.000 сум акча тупларга йөкләмә алганнар иде. Бу йөкләмәне дә намус белән үтәделәр: самолетлар эскадрильясе төзүгә 100.000 сум акча тапшырдылар.

„ИЛ“

ОЧЕРК

Мин аның белән сөйләшергә теләп цехка кергән идем. Ләкин сөйләшә алмадым. Шул кадәр бирелеп, үз эшенә шул кадәр йотылып эшли иде ул, аны бүлдерергә җөрьәт итә алмадым мин.

Ул яңа гына судан чыккан, әле тиешле формага керүдән бик ерак булган киез итекләргә калып суга. Моңарчы бары тик ирләр генә башкара ала торган процесс булып исәпләнгән бу авыр эш, шундый җиңеллек, шундый иплелек белән буйсына бу хатынга, аңа карап сокланып бетә алмассың...

— Менә шушы инде Гөлбану,—диләр миңа.

Шул икәнлегенә ышанам. Моннан дүрт ай гына элек ирләр урынына басып, калыплау эшенә керешкән һәм көнлек нормасын системалы рәвештә ике тапкырдан да ким үтәми торган Хәйруллина Гөлбану шушы икәнлегендә шикләнмим. Аның эше белән, тормышы белән кызыксынам. Бу авыр эшне ничек итеп үзенә буйсындыра алуының серләрен беләсем килә. Ләкин сүз куша алмыйм мин аңа. Аның һәрбер хәрәкәте үлчәнгән, һәрбер секунды исәпләнгән. Оста музыкант кебек эшли ул. Бөтен дикъкать көче белән йотылып, нечкә көйләрне башкаручы скрипкачыны бер генә секунда бүлдереп сүз кушарга мөмкинме соң. Бер генә сүз кушсаң да, шундый сокландыргыч эшнең көе бозылыр, бу түзәл процесс бөтенләй җимерелеп төшәр төсле тоела. Юк, бу минутта аңа сүз кушу җинаять булыр иде.

Хәзергә башка стахановчылар белән танышa торыйм, дигән теләк белән икенче цехка—чистарту цехына керәм. Бу цехта стахановча эшләре белән танылган Латыйповалар, Хәкимуллиналар, Гафаровалар бар. Алар белән сөйләшә торыйм, дим. Ләкин, биредә дә шул хәл. Алар, зур хезмәт күрсәткечләре белән мине кызыксындырган стахановчы хатын-кызлар, яңа гына калыптан чыккан җөнтәй итекләрне, электр көче белән әйләнеп торган кытыршы валикларга ышкытып шомарту эшенә шул кадәр тирән дәрт белән бирелгәннәр, әйтерсең шул эштән башка дөньяда бернәрсә дә юк. Ничек итеп аларга сүз кушасың?

Түшәү цехына керәм. Монда да шул хәл. Юк, биредә кечкенә генә сүз кыстырырлык та урын юк.

Мин эзләгән сер дә шундадыр ахрысы.

—Нинди сер эзлим соң мин?

—«Кызыл тукучы» исемле фабрикасы һәм төрле артельләре—һөнәрчеләре белән данлыклы булган Кукмарада «Иль» исемле кечкенә бер артель бар. Бу артель әле күптән түгел генә оборона заказларын үтәп килгән. Данлы сугышчыларга җылы киез итекләр әзерләп биргән ул. Артель эшчеләре намус белән, сугыш вакытындагыча, фронт таләп иткәнчә эшләп, оборона заказларын срогыннан алда үтәп, производство планын артыгы белән тутырып килгәннәр.

Күптән түгел, артель, оборона заказларын үтәүдән, хезмәт ияләре өчен киң кулланы товарлары—хатын-кыз һәм балалар итекләре эшләүгә күчкән. Бу уңай белән артель алдына яңа кыенлыклар килеп баскан. Моңарчы ирләр итеге басарга көйләнгән калыпларны, бик тизлек белән яңа эш шартларына көйләргә кирәк булган. Аның өстәвенә биредә, тыныч шартларда 100 кеше башкара торган эшне хәзер 55 кенә кеше үтәп бара. Җитмәсә, гадәттә ирләр көче белән генә башкарыла торган авыр процессларда да башлыча хатын-кызлар эшли. Шуларның һәммәсенә дә карамастан, артель үзенең еллык производство планын срогыннан алда үтәп чыга алган.

Менә шуның серен эзли идем мин.

Артель конторасында миңа алдынгы эшчеләрнең фамилияләрен әйттеләр. Председатель Михаил Андреевич Медведев аларның һәрберсен аерып-аерып күрсәтте. Газетада язганда берсен дә төшереп калдырмауны үтенде. Үзенең сәламәтлеге булмау сәбәпле, минем белән бергә цехка керә алмавын, амбулаториягә барырга мәҗбүр икәнлеген аңлатты.

Исемнәр һәм 200 ле, 300 ле цифрлар

Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа җиңүләр белән каршылыйк!

Фронттагы җиңүләр белән рухланып

Кызыл Армиябезнең героик һөҗүмнәре, дошманны тар-мар итеп, яңадан-яңа шәһәрләрне, халык яши торган пунктларны фашизм коллыгыннан азат итүе хезмәт ияләре арасында яңа, көчле энтузиазм тудыра.

14 нче лента-туку фабрикасында кичә генә бик зур митинг булып үтте. Анда фабриканың барлык эшчеләре дә катнаштылар. Минеральные Воды, Пятигорск, Кисловодск һ. б. кебек зур һәм гаять әһәмиятле шәһәрләрнең Кызыл Армия тарафыннан алынуы турында информбюроның махсус белдерүен зал көчле алкышлар белән каршы алды.

Эшчеләр бер-бер артлы трибунага күтәрелделәр. Фабриканың иң яшь эшчеләреннән берсе булган иптәш Чигарева шушы сүзләрне әйтте:

—Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка кушылып мин үз нормаларымны 120 процентка үтәргә йөкләмә алган идем. Хәзер, батыр сугышчыларыбызның Төньяк Кавказдагы зур җиңүләренә җавап итеп, нормаларны 135 процентка үтәргә, ә Кызыл Армия көненә—150 процент итеп үтәргә ирешергә сүз бирәм.

Митингта шулай ук цех начальнигы Гальперин, ремонт-механика бүлеге начальнигы Рубекин һ. б. иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Кызыл Армиянең зур җиңүләре хөрмәтенә танклар колоннасы өчен акча җыю турындагы тәкъдим коллектив тарафыннан бер тавыштан кабул ителде.

КИҢ КУЛЛАНУ ТОВАРЛАРЫН КҮБРӘК ЭШЛӘП ЧЫГАРУ ӨЧЕН

Шушы көннәрдә Чистай шәһәрендә, стахановчылар катнашы белән, партия, хуҗалык һәм профсоюз активы җыелышы булып үтте. Җыелыш, Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган социалистик ярышка бердәм рәвештә кушылу турында карар кабул итте һәм конкрет йөкләмәләр алды. Шәһәр предприятиеләре һәм промартельләре халык өчен киң куллану товарларын Кызыл Армия еллыгына 3,5 миллион сумлык һәм беренче кварталда 5 миллион сумлык күләмдә эшләп чыгаруны үз алларына бурыч итеп куйдылар.

Ш. ШАКИРОВ.

Рәсемдә: алгы планда—жех фабрикасының иң яхшы дискачысы иптәш И. Кузнецов. Ул нормасын һәрвакыт 200 процентка үти.

К. Тахтеев фотосы.

Стахановчы вахтага басып эшлиләр

—Батыр Кызыл Армиябезнең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка бердәм рәвештә кушылып, —ди цехком председателе иптәш Матвеева,—без январь аенда планны 125 процентка үтәргә йөкләмә алабыз.

Баш инженеры иптәш Кадышев булган заводның цехларында үткәрелгән митингларда эшчеләр зур активлык белән катнаштылар һәм үз өсләренә әнә шушылай конкрет йөкләмәләр алдылар.

Начальнигы Ульянова булган цех эшчесе Әхмәтгалиева, нормаларны системалы рәвештә 110 процентка үтәп бару турында йөкләмә алып, металлистларны ярышка чакырды, аларның цехны кирәкле металлар белән токтаусыз тәэмин итеп торуларын таләп итте. Металлистлар бу чакыруны бердәм рәвештә кабул иттеләр.

Завод коллективы тулы килеш үз өстенә түбәндәге йөкләмәләрне алды:

Барлык цехларның да график буенча төгәл эшләүләренә ирешеп, январь ае планын 120 процентка, Кызыл Армия көненә—123 процентка һәм беренче квартал планын—126 процентка үтәргә.

Авыр эшләргә механизация кертү, технология процессларын яхшырту, производствоны рационализацияләштерү исәбенә, бер данә изделие эшләп чыгаруга китә торган вакытны 2 процентка киметергә.

Дефицитлы материаллар урынына алмаштыргычлар куллану, нык экономия режимы үткәрү юллары белән, продукциянең үзенә төшү бәясен беренче кварталда 0,5 процентка киметергә.

Беренче кварталда, 100 мең сум экономия бирерлек 10 рационализация тәкъдиме булдыруга ирешергә.

Тегү-монтаж производствосы буенча 50 кешене, металл производствосы буенча 78 кешене техминимум курслары аркылы үткәрергә, һөнәр училищесыннан 24 укучыны өйрәтүне төгәлләргә һәм аларны кадровый эшче итеп күчерергә һ. б.

Соңгы вакытларда чимал белән тәэмин итүдә заводта кайбер тоткарлыклар килеп туган иде. Хәзер барлык производстволар кирәкле чимал белән тулысынча тәэмин ителгән. Завод коллективы, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка бердәм рәвештә кушылып югары темпларны яулап алуга ирешү, алынган йөкләмәләрне намус белән үтәү өчен барлык көчен биреп эшли. 1942 нче елда еллык планны 9 нчы ноябрьда ук төгәлләп чыккан бу гүзәл коллектив үз сүзен большевикларча үтәр. Заводта 15 нче январьдан башлап сталинчыл вахта игълан ителә.

белән генә канәгатьләнмичә, цехка кергән идем. Стахановчыларның сокландыргыч эшләре, мин эзләгән серне нәрсәдә булуын сүзсез аңлаттылар.

Шулай да, сүз кушарга мөмкин булган кешеләр дә таптым мин. Кайсыдыр цехта бер карт очрады миңа. Стахановчылар белән кызыксынуымны сизеп алгач, ул аталарча кайгыртучанлык белән, теге яки бу эшчегә ымлап-ымлап күрсәтергә тотынды.

—Менә бу эшчегә игътибар итегез,—диде ул, бик нык тырышып, киез итекләр калыплаучы какча кешене күрсәтте.—Шәфиков ул. Иң алдынгы стахановчы. Менә бу Хәйруллинаны да шулай эшләргә ул өйрәтте.

Аннары ул мине ашыктырып юу цехына алып китте.

—Кара син менә бу хатынга,—диде ул. Мунча эче кебек парга күмелгән цех эчендә, озын кара чәчләре юешләнеп иңнәренә төшкән хәлдә, чаңнан чыккан калыпсыз киез итекләрне машина белән язып торучы яшь хатынны күрсәтте. —Кәримова бу. Ирләр генә эшли торган эшне шундый осталык белән башкара.

Түшәү цехында Салихованы күрсәтте ул миңа. Кечкенә гәүдәле бу хатын берьюлы ике биргадада эшләп, ике кеше эшен бер үзе башкару җаен тапкан...

Карт шулай дәртләнеп-дәртләнеп мине цехтан-цехка йөртә, артельнең алдынгы эшчеләрен берәм-берәм күрсәтә иде. Ул арада минем яныма кулы гарипләнгән таза гәүдәле бер яшь ир килеп туктады. Картка сиздерми генә ымлап:

—Бу картның үзе турында да онытмагыз,— дип куйды ул миңа.

—Кем соң ул карт?

—Цех мөдире ул. Федор Захарович. 63 яшендә.

—Кайсы цехта?

—Калыплау цехының мөдире исәпләнә, ләкин бөтен артельгә бер үзе ул. Бөтен цехларга да бер үзе хезмәт күрсәтә.

Ахырда гарип куллы кешенең үзе белән дә кызыксынырга туры килде. Производство мөдире Богомолов булып чыкты ул. Ул Ватан сугышы инвалиды икән. Сугыштан кайткач аңа җиңелрәк хезмәт бирергә теләгәннәр. Ләкин ул аны теләмәгән: —20 ел киез итек производствосында эшләдем, шул эшемнән аерыласым килми,— дигән. Аны шушы артельгә җибәргәннәр. Һәм ул биредә бер үзе 3—4 кеше хезмәтен алып бара.

— Бу эшчеләр белән кайчан сөйләшеп алырга мөмкин булыр икән соң?—дидем мин.

— Озакламый төшке ашка туктарлар, —диде Богомолов.

Ләкин төшке аш вакыты да күп нәрсә бирә алмады миңа. Стахановчыларның тәнәфес вакытлары да ничектер, иркенләп сөйләшеп торырга мөмкинлек бирми торган булып чыкты. Ашыгыч-ашыгыч сөйләшүләрдә әйтелгән берничә сүз мин белергә теләгәннәрнең барын да әйтеп бирде.

— Эш тә җиңел түгел, тормыш та җиңел түгел,—диделәр алар,—тик авырлыклар белән исәпләшә торган чак түгел шул. Немец җиңелгәч җиңел булыр.

— Ничә сәгать эшлисез?

— Сәгатьләп тора торган чак түгел, эшне бетергәнче эшлибез.

Искиткеч гүзәл эшләре белән хәйран калдырган стахановчы хатын-кызлар бу җавапларны миңа узып барышлый гына диярлек әйтеп уздылар...

Председатель Михаил Андреевич белән тулырак сөйләшергә теләп, икенче тапкыр артельгә килгәч, миңа: «Михаил Андреевичның сәламәтлеге бик начар, ул больничныйда ята»,—диделәр. Кайтып килгән вакытта миңа Михаил Андреевич үзе очрады. Таякка таянган хәлдә акрын гына атлый, артельгә таба китеп бара иде ул.

— Күңел тынычланып бетми бит, барып карыйсы килә,—диде ул миңа.

Әйе, алар бары да үз эшләре өчен яналар. Киң куллану товарлары да, ил өчен кирәк икән, фронт заказлары кебек ук әһәмиятле икәнен аңлыйлар алар.

Әйе, хезмәт фронтында аз көч белән дә зур планнарны җиңеп чыгуның сере, алдына куелган бурычның әһәмиятен аңлауда, чорга хас булган шартларны истә тотып, берни белән дә исәпләшмичә эшләүдә шул.

МИРСӘЙ ӘМИР.

Уку өе һәм клуб колхозның культура учагы булырга тиеш

Саба районы, «Игенче» колхозының уку өендә (мөдире иптәш Нигъмәтуллина) эш яхшы оештырылган. Уку өе советы эшен план нигезендә алып бара. Һәркөнне колхозчыларга Совет Информбюросы материаллары укыла. Белешмәләр өстәле оештырылган. Колхозчылар аннан үзләренең һәрбер сорауларына җавап таба алалар. Былның 10 ае эчендә укытучылар көче белән колхозларда халыкара хәлләр турында 25, ватан сугышы һәм сугыш шартларында колхозчы-крестьяннарның бурычлары темасына 31, медицина-санитария темасына 13 доклад һәм беседалар үткәрелгән, һәм аларда 4.300 кеше катнашкан. Уку өе янында ПВХО һәм ГСО түгәрәкләре оештырылды. 62 кеше ГСО значогына норма тапшырдылар.

Ләкин хәзерге шартлар таләп иткәнчә эшне оештырган уку өе һәм клублар саны районда бик аз әле. «Кызыл көрәш» һәм Каганович исемендәге колхозларда уку өе һәм клублар бар. Ләкин алар атнага бер генә тапкыр да ачылмыйлар. Район үзәгендәге көтепханә һәм үзәк клуб берничә еллардан бирле яшәп килә. Көтепханә (мөдире иптәш Мәрданова) иртәнге 8 сәгатьтән кичке 3 сәгатькә һәм 3 тән кичке 10 сәгатькә кадәр ачык булырга тиеш. Көтепханә өзлексез хезмәт күрсәтсен өчен район мәгариф бүлеге ай саен 320 сум түләп ике кеше тота. Ләкин көтепханә көндез салкын дип, кич белән керосин юк дип ачылмый. Үзәк клуб (мөдире иптәш Хәсәнова) район советы башкарма комитеты һәм райком җыелышлары булганда гына ачыла. Шуның нәтиҗәсендә яшьләр һәм кызлар эштән буш вакытларын файдасызга йөреп үткәрәләр. Алар арасында бер төрле дә политик-масса эшләре алып барылмый. «Яблаштау» һәм «Сәрдә» колхозларының уку өйләрендә дә яшьләрне тупларлык, тәрбияләрлек бернәрсә дә оештырылмый. «Саурош» колхозының уку өе мөдире бер ук вакытта кибетче дә, хат йөртүче һәм фуражер булганлыгы өчен хезмәт хакы ала. Ләкин ул аларның берсен дә эшләми. Аны тикшерүче дә юк.

РОНО мөдире иптәш Девитьяров уку өе һәм клубларның эше белән җитәрлек кызыксынмый.

Уку өе һәм клублар колхозның культура учагы булырга тиешләр. Район мәгариф бүлеге һәм ВЛКСМ райкомы аларның эшен сугыш шартлары таләп иткәнчә оештырырга тиешләр.

Ф. Г.

ИСААК НЬЮТОН ИСЕМЕНДӘГЕ СТИПЕНДИЯЛӘР

РСФСР Мәгариф халык комиссариаты, Исаак Ньютонның тууына 300 ел тулуны искә алып, университет студентлары өчен һәрберсе 400 сумнан 15 стипендия билгеләде. Стипендияләр физика, математика, механика һәм астрономия буенча специаллашучы һәм аеруча уңышлар күрсәтүче студентларга биреләчәк. Москваның М. В. Ломоносов исемендәге дәүләт университетына һәм Ленинград дәүләт университетына өчәр стипендия билгеләп куелды.

СУД

САБОТАЖ ЯСАУЧЫ

Л. Д. Васильева дигән хатын шушы елның сентябрь аенда Казан киез итек фабрикасына эшкә алынган булган. Ләкин ул намус белән эшләү урынына контрреволюцион саботаж юлына баскан. Васильева сентябрь аенда ике тапкыр прогул ясаган һәм 24 нче сентябрьдән алып 2 нче октябрьга кадәр сәбәпсез эшкә килмәгән өчен, халык суды тарафыннан 6 айга мәҗбүри хезмәткә хөкем ителгән. Шуңа да карамастан Васильева саботаж ясауда дәвам иткән. Ул ике ай эчендә 7 тапкыр прогул ясаган һәм соңыннан фабрикада эшләүдән бөтенләй баш тарткан.

Васильеваның эше шушы көннәрдә Татарстан АССР Верховный Судында каралды. Суд аны 10 елга төрмәгә ябарга һәм җәза срогын тутырганнан соң сайлау-сайлану хокукыннан 2 елга мәхрүм итәргә хөкем итте.

Сугыш припаслары житештерә торган Н-че завод 1942 нче ел планын срогыннан элек үтәп, яңа елга кадәр фронтка планнан тыш меңнәрчә снарядлар бирде. Рәсемдә: комсомолка Александра Колмакова снарядларны кабул итә.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

12 нчә ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

12 нче январьда безнең гаскәрләр Төньяк Кавказда, һөҗүмне дәвам иттереп, Ессентуки шәһәрен һәм тимер юл станциясен, халык яши торган зур пунктлардан Ессентукскаяны, Левокумскийны, Каррасны, Николаевскаяны, Бештаунитны алдылар.

Зимовники районында безнең гаскәрләр халык яши торган Ново-Николаевская, Харьковский, Майсрский, Курмоярский пунктларын алдылар.

Донның түбәнге агымы районында һәм Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүмне дәвам иттерделәр.

* * *

11 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 5 танкысын, 30 дан артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 тимер юл составын җимерделәр һәм бер ротага якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары немецларны тагын беничә урамнан бәреп чыгардылар һәм 20 ДЗОТ ны, 37 блиндажны алдылар. 2 орудие, 19 пулемет, танкка каршы ата торган 4 мылтык, автоматлар һәм винтовкалар кулга төшерелде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта дошман контратакага шактый күп танклар һәм пехота җибәрде. Бик каты сугыш бер тәүлек дәвам итте. Немецлар, совет частьларын уңайлы позицияләрдән ничек кенә итеп булса да бәреп чыгарырга омтылып, үзләренең резервларын сугышка керттеләр. Безнең сугышчылар, нык торып, дошманны хәлсезләндерделәр, ә соңыннан аңа көчле удар ясадылар. 2.000 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары, 40 ка якын танк һәм 12 орудие юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр үзләренең позицияләрен яхшырттылар һәм дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Лукидан төньяк-көнбатыштарак немецлар Н-че часть саклап тора торган позицияләргә контратака ясаганнар иде. Дошман пехотасы пулемет һәм мылтык уты белән каршы алынды һәм җиргә ятарга мәҗбүр булды. Шул ук вакытта немец танклары мина кырына килеп керделәр. 2 танк миналарга бәрелеп шартлады, ә калган 5 танкны безнең танкка каршы ата торган артиллериябез сафтан чыгарды. Кичкә таба гитлерчылар, бу сугышта 200 дән артык үтерелгән кешеләрен калдырып чигенделәр. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошманга атака ясадылар, бер ротага якын немец пехотсын кырдылар, 14 пулемет, бер самоход пушка, 40 автомат, күп винтовкалар һәм сугыш припаслары склады кулга төшерделәр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы рәвештә алга бардылар. Немецлар, үзләренең таркалган частьларын тәртипкә китерү өчен, бер уңайлы чиктә торып калырга маташтылар, ләкин безнең танк һәм кавалерия частьларыбызның удары белән аударып ташландылар. Н-че кавалерия часте сугышчылары, чигенүче дошманны куып барып, 200 дән артык гитлерчыны кырдылар, 7 орудие; 30 автомашина һәм 4 сугыш припаслары склады кулга төшерделәр. Безнең икенче бер частебыз дошманның бер батальон пехотасын тар-мар итте, 4 автомат пушка, 4 миномет, 47 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерде.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары немецларның гаскәрләр, сугыш припаслары һәм сугыш техникасы төялгән 6 тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә 5 паровоз, 52 вагон һәм 39 платформа җимерелгән. Җимерек вагоннар астында калып күп гитлерчылар үлгән. Икенче бер отрядның партизаннары дошманның зур көчләренә каршы бик каты сугышта 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырганнар.

* * *

Түбәндә Кабардино-Балкария АССР ның башкаласы булган Нальчик шәһәрендә немец-фашист кабахәтләр эшләгән канлы җинаятьләр турындагы акт игълан ителә: «Үткән елның көзендә шәһәргә басып кергәннән соң гитлерчылар шәһәр халкын таларга һәм үтерергә керештеләр. Беренче көннәрдә үк фашист ерткычлар кызылармеец Шауловның хатынын, 5 айдан 11 яшькә кадәр булган биш баласын үтерделәр. Михо Шамилогны һәм аның 10 яшьлек улын, шулай ук шәһәрнең башка күп кешеләрен аттылар. Фашист көчләүчеләр 14 яшьлек укучы В. ны мыскыллладылар, 16 яшьлек Н. ны көчләделәр. Бераз вакыт үткәннән соң немецларның хәрби властьлары шәһәр гражданнарын—русларны, кабардаларны, балкарларны, осетиннарны, грузиннарны, еврейләрне һәм башкаларны күпләп атарга һәм кырырга тотындылар. 1943 нче елның 5 нче январында шәһәргә Кызыл Армия частьлары кергәннән соң шәһәрдән 6 километр ераклыкта, танкка каршы казылган чокырларда һәм ерак каберлектә немецлар тарафыннан тәткәләнгән һәм имгәтелгән 600 дән артык үле гәүдә табылды. Гитлерчы бандитлар аларның күбесенең кулларын, аякларын, колакларын кисеп алганнар; күзләрен чыгарганнар. Фашист палачларның корбаннары арасында бик күп балалар бар. Беренче алынган саннарга караганда, немец-фашист юлбасарлар кулыннан Нальчик кешеләреннән кимендә 2.000 кеше һәлак булган. Немец оккупантлар кабарда-балкар драма театрын, педагогия училищесын, медицина мәктәбен, 9 мәктәпне, пионерлар һәм октябрятлар йортын, республика көтепханәсен, яңа больницаны, поликлиниканы һәм башка төрле культура һәм дәвалау учреждениеләрен шартлатканнар һәм яндырганнар. Варварлар Нальчикның курорт шәһәрчеген—санаторийларны, ял йортларын, дәвалау кабинетларын җимергәннәр һәм яндырганнар, барлык памятникларны юк иткәннәр, шәһәр паркын кисеп бетергәннәр, водопроводны эштән чыгарганнар һәм республиканың бик күп культура кыйммәтләрен Германиягә алып киткәннәр». Актка Нальчик шәһәре гражданнарыннан С. Ифраимов, Л. Ашуров, П. Шабаев, М. Моисеева, Е. Давыдова, А. Либман, П. Ифраимов, М. Шалумов, М. Ифраимов, Ш. Давыдов һәм Д. Левиевлар кул куйган.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӨҖҮМЕ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

АНГЛИЯ

ЛОНДОН, 11 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәрби күзәтчесе генерал Губерт Гоф, Кызыл Армия частьларының һөҗүме турындагы хәбәрләргә аңлатмалар биреп, болай дип яза: «Сталин һөҗүм итү өчен моментны үрнәк булырлык түземлелек белән һәм солдатның психологиясен тирәнтен аңлау белән сайлап алды. Ул һөҗүм юнәлешен немец армияләре өчен һәлакәтле төстә сайлап алды. Ул резервларны туплады һәм аларны кискен төстә дошманга каршы ташлады. Руслар искиткеч тизлек белән алга баралар. Бу—союзниклар өчен сабак».

«Санди таймс» газетасының авиация күзәтчесе Кызыл Армиянең хәзерге һөҗүмендә совет авиациясенең күренекле роль уйнавын күрсәтеп үтә. Күзәтче, совет авиациясе чынлыкта Германия җитештереп өлгерүгә караганда күбрәк самолетларны юк итә, ди һәм, бу инде Көнбатышта һәм Урта диңгез бассейнында да хис ителә, дип өсти.

АКШ

НЬЮ-ЙОРК, 11 январь. (ТАСС). Американың Кливленд шәһәрендә чыга торган «Плейн дилер» газетасы болай дип яза: «Руслар бик яхшы стратегияне тормышка ашыралар. Алар дошманны аптырашта калдырдылар. Кызыл Армия частьларының һөҗүме инде Африкадагы Англия—Америка гаскәрләренә зур ярдәм күрсәтте. Русларның һөҗүме Гитлерга союзникларның Европага басып керүләренә каршы тору өчен үзенең гаскәрләрен Совет—Германия фронтыннан алырга мөмкинлек бирмәс». Газета берләшкән илләрне әлегә кадәр сугышның төп авырлыгын үз җилкәсендә күтәреп баручы Россиягә карата үзләренең бурычларын үтәргә чакыра.

ЛАТИН АМЕРИКАСЫ

НЬЮ-ЙОРК, 11 январь. (ТАСС). Кубада Гавана шәһәрендә чыга торган «Нотисиас де Ой» газетасы болай дип яза: «Хәзер союзникларның кораллы көчләренең, советларның кораллы көчләре белән берлектә, дошманны тәмам җиңү өчен, кайчан гына булганга караганда да күбрәк активлык күрсәтүләре кирәк».

Эквадорда, Гвиакил шәһәрендә чыга торган «Эль универсо» газетасы болай ди: «Советларның җиңүле һөҗүме Эквадор халкының киң массасында шатлык тудырды. Дошман өчен Кызыл Армия бик уңайсыз хәл китереп чыгарды. Германия армияләре шактый йомшадылар».

Яңа Гвинея якынында зур һава сугышы

ЛОНДОН, 11 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Яңа Гвинея ярлары турысында зур һава сугышы булган. Сугыш 9 нчы январьда союзникларның җиңүе белән беткән. Японнар, Лаедагы япон гарнизонына ярдәмче көчләр алып баручы пароходларга һавадан булышлык күрсәтергә маташкан чакта 9 нчы январьда 39 истребительләрен һәм, ихтимал, тагын 17 самолетларын югалтканнар. Союзниклар авиациясенең югалтулары күп түгел. Япон пароходларына союзниклар авиациясенең өч көнлек һөҗүмнәре вакытында японнар 77 самолет югалтканнар.

Макартур штабы вәкиленең белдерүенчә, 9 нчы январьда союзниклар авиациясе японнар кәрванына каршы, шулай ук яр буендагы һәм Лае аэродромындагы япон объектларына каршы аз дигәндә 16 атака ясаган. Японнарның 6 транспортыннан 3 транспорт батырылган. Ләкин японнар 8 нче январьда бераз гаскәр төшерә алганнар. 9 нчы январьда японнар тагын бераз гаскәр төшергәннәр. Хәзер инде японнар кәрванына каршы хәрәкәтләрне тәмам булган дип санарга мөмкин, чөнки кәрванның нигездә озата баручы пароходлардан торган калдыкларының соңгы тапкыр Лаедан төньяк-көнчыгышка таба китеп барганнарын күргәннәр.

Төньяк Африкада Франция гаскәрләренең хәрәкәтләре

ЛОНДОН, 11 январь. (ТАСС). Марокко радиосы Төньяк Африкадагы Франция гаскәрләре штабының белдерүен тапшыра. Белдерүдә Франция гаскәрләренең Триполитаниядә Тану-Мелене һәм Тасионены алганлыклары әйтелә. Тунисnúmта, Пишуннан төньяк-көнчыгышка таба булган районда, французлар, немецларның атакасын кире кайтарганнар һәм дошманның кечерәк бер гарнизонын таркатканнар. Дошман атакага катнашкан 4 танкысыннан өчесен югалткан. Кайруаннан көнбатыштагы һәм Пон-дю-фастан көньяктагы районнарда авиация актив хәрәкәт иткән.

Кытайда экстерриториальлек хокукын юк итү турында Англия белән Кытай арасындагы договорга кул кую

ЛОНДОН, 11 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Чунцинда Англиянең Кытайдагы экстерриториальлек хокукын юк итү турында Англия белән Кытай арасындагы договорга кул куелган.

Договорда күрсәтелгәнчә, сугыш хәрәкәтләре тәмам булганнан соң беренче алты ай эчендә дуслык турында, сәүдә, диңгездә йөрү һәм консульлык хокуклары турында договор төзү өчен сөйләшүләр башланырга тиеш.

Бу договорга Чунцинда Кытайның чит ил эшләре министры Сун-Цзы Вен һәм Бөек Британиянең Кытайдагы илчесе Сеймур тарафыннан кул куелган

ВЕНГРИЯДӘ МАССОВЫЙ КУЛГА АЛУЛАР

ИСТАМБУЛ, 11 январь.(ТАСС). Будапешттан хәбәр итүләренә караганда, анда 23 нче декабрьга каршы төндә массовый облавалар һәм тентүләр булган. Шул вакытта 320 кеше кулга алынган.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

—Буэнос Айрестан Аргентинаның элекке президенты генерал Хустоның үлгәнлеген хәбәр итәләр.

—Төньяк Африкада Франция көчләрен яңадан коралландыру комитеты төзелә. Комитет Америка, Англия һәм Франция офицерларыннан торачак.

— Канада армиясендә хатын-кызлар корпусы 1942 нче елны 800 кешедән 8.000 кешегә җиткән. Хатын-кызлар бик күп хәрби белгечлекләрне үзләштергәннәр. Алар шофер, механик, телефонистка, радиооператор һ. б. булып эшлиләр.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген премьера—„Мәрьям“. 2 нче номер штамп сугылган билетлар белән керергә ярый.

Зур драма театры. Бүген—„Күренми торган ханым“. 14 нче январьда—„Эзләнгән кеше“.

Татар дәүләт филармониясе. Менжинский исемендәге клубта бүген һәм 14 нче, 16 нчы һәм 17 нче январьда — Молдавия дәүләт джазы концертлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген чегән ансамбле катнашы белән зур цирк тамашасы. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — Америка фильмы —„Сиңа сокландым“.

„Унион“—„Алтмыш тугызынчы параллель“.

„Пионер“ көндез — „Конек-Горбунок, кич — „Волга-Волга“.

„Чаткы“ — „Корыч ничек чыныкты“.

„Кызыл йолдыз“— „Гроза“.

ПФ610 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 74